КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1286

2024 елга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга түбәндәгеләрне билгеләргә:

транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен 605 сум күләмендә;

балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен 369 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билетны тулыландыру кыйммәтен билгеләү турында» 2022 ел, 27 декабрь, 1423 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин